| Республика Татарстан<br>Зеленодольский<br>муниципальный район<br>Исполнительный комитет<br>Нижневязовского городского<br>поселения | Татарстан Республикасы<br>Зеленодол муниципаль<br>районы<br>Карамалы тау шэһэр<br>жирлеге башкарма<br>комитеты |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** пгт Н. Вязовые **КАРАР**

**09.12.2019** **№197**

2019 елның 24 июнендәге 148 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты карарының 1 пунктының үз көчен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Түбән Карамалы шәһәр җирлеге башкарма комитеты карарының 1 пунктын - үз көчен югалткан дип таныргa.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70нчы йорт, җирле үзидарә бинасы, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче Май ур., 70 нчы йорт (җирлекнең административ бинасы), Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Беренче май ур., 30 нчы йорт, «Гадел» кибете янында мәгълүмат тактасы, Карамалы Тау штп, Беренче Май ур., вокзал алды мәйданчыгында мәгълүмат стенды, Кузнечная ур., 13 а йорт, «Диана» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Кузнечная ур., 16 а йорт, «Рубин» кибете янында мәгълүмат стенды, Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Б.Кочемирская ур., 2а, «ЮСОН» кибете янында мәгълүмат стенды, Протоповка авылы, Кооператив урамы, 15 нче йорт, ИП Яфизов кибете янында мәгълүмат тактасы, Олы Ходяшево авылы, Үзәк урам, 42 нче йорт, ИП Навасардян кибетендә мәгълүмат тактасы.

**Җитәкче** **А.М. Гыйниятов**